СӨЙ ГОМЕРНЕ, СӨЙ ХАЛЫКНЫ, СӨЙ ХАЛЫКНЫҢ ДӨНЬЯСЫН!

# ДУСЛЫК

ОКТЯБРЬ РАЙОНЫ ИҖТИМАГЫЙ - СӘЯСИ ГАЗЕТАСЫ.
ОБЩЕСТВЕННО-ПОЛИТИЧЕСКАЯ ГАЗЕТА ОКТЯБРЬСКОГО РАЙОНА.


4 июнь, 1997 ел.
ЧӘРШӘМБЕ

Газета 1931 елның 9 июленнән бирле чыга. | № 60 (8072) | Бәясе билгеләнгәнчә


# ОЛЫ ТОРМЫШ КӨТӘ АЛАРНЫ

## МӘКТӘПЛӘРДӘ ЧЫГАРЫЛЫШ ИМТИХАННАРЫ БАРА. 2 ИЮНЬДӘ 11 КЛАСС УКУЧЫЛАРЫ ИНША ЯЗДЫЛАР





Норлатның 2 нче рус - татар мәктәбендә 4 чыгарылыш классында ул биремне 102 укучы башкарды, аның 12се - «алтын» һәм «көмеш» медальләргә кандидатлар. Иртәнге 9 сәгатьтә алар өч тыгыз рәткә тезелделәр, һәм мәктәп директоры Анатолий Александрович Евлентьев дулкынланган укучылар һәм педагогларның игътибарлы карашы астында министр тексты язылган тар кәгазьне тартып чыгарды. Укыту эшләре мөдире Татьяна Николаевна Маслова аны укыганда, киеренкелек бераз кимеде төсле: темалар җидәү һәм төрледән - төрле. Бердән, классиклар - Л.Н.Толстой, А.С.Пушкин, А.П.Чехов. Болар, безгә калса, мәңгелек темалар. Аннан соң рус әдәбиятында зур шәһәр темасын ачу, М.А.Шолохов иҗаты турында фикерләр белән бүлешү һәм укыган китапларының берсенә рецензия язу тәкъдим ителгән иде. Традицион ирекле тема да бар: «Башкалар бәхете турында кайгыртып, без үз бәхетебезне табабыз» (Платон). Бусы әдәби материалларга гына түгел, тормыш тәҗрибәсенә таянуны да таләп итә иде. «Мин сезнең әдәби материалларга күбрәк игътибар бирүегезне сорар идем, сезнең тормышыгыз алда бит әле»,- диде мәктәпнең рус теле һәм әдәбияты укытучысы Айнур Җиһаншевна Җамалетдинова. Моның белән килешми мөмкин түгел. Ә әлегә укучылар алдында бер бурыч: 6 сәгать буена инша язу бурычы тора иде. Мөстәкыйль рәвештә грамоталы, мәгънәле итеп язу. Эш башланып 1 сәгать үткәч, һәр укучы әдәби әсәр текстларыннан, ә эшне тапшыруга 1 сәгать кала - һәртөрле лингвистик сүзлекләрдән файдалану мөмкинлеге алачак. 3 сәгать үткәч, кайнар төшке аш биреләчәк иде. Ә әлегә әле һәрберсе алдында беренче укытучылары тарафыннан бүләк ителгән шоколадлар ята. Ә класста - ак сирень исе һәм, билгеле, иҗат рухы хөкем сөрде.



## «Яшүсмер» ишекләрен ачты

Агымдагы дүшәмбедән район мәгариф бүлеге каршындагы «Яшүсмер» профиль лагере эшли башлады. Беренче агымда 60 бала ике группага тупланып, футбол белән шөгыльләнәчәк. Тагын 30 бала «Лидер» группасына туплandылар.

Өстәмә белем бирү учреждениеләре базасында эшләячәк әлеге лагерьда ял итүче балалар ярдәмче интернат - мәктәптә яшәячәкләр. Балаларны туклandыру мәсьәләсе дә хәл ителгән. Һәр группаның үз программасы бар. Балаларны ял иттерү, сәламәтләндерү, төрле профильле түгәрәкләрдә шөгыльләнүләрен оештыру, буш вакытларын кызыклы итеп оештыру - лагерь педагогларының төп максатлары шулар.

## Телефоның булса,..

1 июньнән аннан файдаланган өчен ай саен 20 мең түли башлаячакбыз. Бу Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 1997 елның 28 маенда кабул иткән «Элемтә хезмәтләре өчен тарифлар турында»гы 408 нче карары нигезендә башкарыла.

## Ышанычлы яклау

Районда полиомиелитны 2000 нче елга тулысынча юкка чыгару программасының бер өлеше булган иммунлаштыруның икенче этабы төгәлләнде. Бу юлы вакцина 3 яшькә кадәрге 1956 баланы (учетта 1962 бала тора) яклады. 6 сабыйның медицина кичектерүе бар. Белгечләр этапның һәр табиблык участогында да уңышлы үтүен раслыйлар, шуңа районда санэпидкүзәтү Дәүләт комитеты тарафыннан активлар исәбендә билгеләнде.

## Хөрмәтле укучыларыбыз!




Дус булыйк, «Дуслык»лы булыйк!

## Күрүче юкмы?

Тимер юл поселогында, Суворов урамында мәчеткә каршы кызыл төстәге билгесез ВАЗ - 2106 машинасы хатын - кызны бәрдерә. Күрүчеләр булса 02, 2 - 15 - 50 яки 2 - 11 - 25 телефоннары аша хәбәр итүләрен сорыйбыз. Анонимлыкны гарантиялибез.

## ҮЗӘКТӘ - ЧӨГЕНДЕР ҺӘМ КУКУРУЗ

### Уңыш - 97

### матбугат үзәге хәбәр итә

**Вакытның үткәне сизелми дә. Әле кайчан гына сабан ашлыгы чәчүлекләрен өстәмә туклandыруны үзәккә куйсак, бүген инде шикәр чөгендере басулары да төп игътибар бирүне сорый. Хуҗалыкларның өчтән берендә чөгендер чәчүлекләрендә шаровкалау эшенә тотындылар. «Чирмешән», «Рассвет», «Кондырча», «Родина» хуҗалыкларында бу агрочара 200 - 100 гектарда уздырылды, аларның беренче икесендә, шулай ук Синдряков исемендәге, Хафизов исемендәге хуҗалыкларда чөгендерне сирәкләү эшенә дә тотындылар. Һәр өченче хуҗалыкта кукурузның рәт араларын эшкәртү дә бара. «Рассвет», Мичурин исемендәге, «Таң», «Алга» хуҗалыкларында бу чара 110 - 160 гектарда уздырылды инде.**

**Бер үк вакытта күпьеллык үләннәрне ясалма сугару да игътибар үзәгендә булырга тиеш.**

## ӘЛЕ БУ ЧИК ТҮГЕЛ

Районда сыерлардан көнлек савымның күптән шулай югары күтәрелгәне юк иде инде. Һәм сөт җитештерүчеләребезнең республикада иң алдынгы урыннарга ышанычлы атлауларында бернинди дә очраклылык юк. Сөт савуның малларны җәйләүгә күчергәч күзгә күренеп артып китүен билгеләп үткән идек инде. Бу эшне кем тизрәк тотты, шул отты быел. Анысы мәгълүматлардан ачык күренә. Саннарның беренче баганасы 2 майда, икенчесе - 2 июньдә бер сыердан савылган сөт, өченчесе - былтыр 2 июньдә савылганнан күпмегә артык (килограммнарда).

| | | | |
|---|---|---|---|
| «Кондырча» | 18,1 | **23,0** | + 7,1 |
| «Дуслык» | 21,8 | **22,3** | + 3,3 |
| Мичурин исем. | 16,0 | **19,5** | + 6,0 |
| «Агрохимсервис» ярд. хуҗ. | 13,6 | **17,0** | + 5,2 |
| «Якты Күл» («Норлат» а/ф) | 12,5 | **16,3** | + 6,0 |
| Хафизов исем. | 11,7 | **14,8** | + 4,7 |
| «Рассвет» («Норлат» а/ф) | 12,9 | **14,7** | + 4,4 |
| Муса Җәлил исем. | 9,7 | **14,0** | + 3,6 |
| «Чирмешән» | 10,7 | **13,7** | + 3,2 |
| «Киекле» | 10,6 | **13,6** | + 4,3 |
| «Шикәр заводы» ярд. хуҗ. | 12,4 | **13,3** | + 5,1 |
| Синдряков исем. («Норлат» а/ф) | 10,2 | **13,2** | + 3,6 |
| Кузнецов исем. | 8,9 | **13,1** | + 3,1 |
| «Заветы Ильича» | 10,4 | **13,0** | + 3,3 |
| «Сөт - май» ярд. хуҗ. | 8,3 | **12,7** | + 2,9 |
| «40 лет Победы» | 7,8 | **12,4** | + 2,9 |
| «Родина» | 10,1 | **12,3** | + 1,5 |
| «Татарстан» | 8,3 | **11,4** | + 3,9 |
| «Заря» | 8,4 | **11,4** | + 3,3 |
| «Үрнәк» | 7,0 | **11,0** | + 1,1 |
| «Төрнәс» | 10,7 | **10,7** | + 1,9 |
| »Мамык» (РСУ) | 9,1 | **10,6** | + 5,4 |
| «Әлмәт» | 7,1 | **10,2** | + 3,0 |
| «Алга» | 6,6 | **10,0** | + 5,9 |
| «Таң» | 8,1 | **9,8** | + 1,1 |
| Строитель (МСО) | 6,7 | **9,3** | + 2,1 |
| «Комбайн» | 6,0 | **8,7** | + 4,3 |
| «Правда» (Нефтебаза) | 5,6 | **8,0** | + 1,0 |
| «Игенче» | 6,5 | **8,0** | + 1,9 |
| **Район буенча** | **10,0** | **12,9** | **+ 3,8** |

Әмма малларны җәйләүгә күчерү сөтне үзеннән үзе генә арттырмый, билгеле. Иң элек сыерларның рационын баету турында көндәлек кайгыртырга кирәк. Беренче этапта сөтне шактый ишәйткән ужымнарга хәзер малларның әллә ни исе китми инде, шуңа күрә яшел конвейерның башка буыннары да эшкә җигелергә тиеш. Киекле, Муса Җәлил исемендәге һәм кайбер башка хуҗалыкларда савым көтеп күпьеллык үлән басуларына күчереп дөрес эшләделәр, мөмкинлеге булган хуҗалыкларда сыерларны табигый болынлыкларда көтәләр. Әмма малларның потенциаль мөмкинлеген файдаланып калу өчен аларга күпьеллык үләннәрне тураклап чабып алып кайтып салу да кирәк, калган ужымнарны да урып алып өстенә тозлы су яки патока эремәсе сибеп бирсәң, ашалып бетәсе шиксез. Тоз дигәннән, лагерьларда анысының гел булып торуы шарт. Сыер организмына көнгә 200 - 250 грамм тоз кирәк һәм бу сөт артуның мөһим алшарты булып тора. Тозны махсус урынга түбә астына кую мөһим. Кайбер хуҗалыкларда сыерларны судан өзмәскә дигән таләп төгәл үтәлеп тә җитми әле. Бер үк вакытта малларны әле саламнан да өзмәскә кирәк. Сыерларны көтүдә йөртү мәсьәләсенә килгәндә, аларны кичке савымнан соң кардаларда пычракта яткызуга караганда аланлыкка яки болынлыкка алып чыгу, таң атканда савымга кадәр дә йөртеп алу файдага гына. Бер үк вакытта кышлату чоры турында да кайгырта башларга бик вакыт. Сүз бу эшнең әле әллә ни өстәмә чыгым сорамый торганы - кычыткан, әрем һәм башка дару үләннәре җыеп киптереп кую, яфрак азык туплый башлау турында. «Якты Күл», Хафизов исемендәге, Синдряков исемендәге, «Родина», «Правда» һәм башка хуҗалыкларда бу эш уңышлы гына бара. Кышын маллар организмы кирәкле витаминнарга бай өстәмә азыклы да булыйк, яшь үрчемне исән - сау үстерү өчен һичшиксез кирәге чыгачак дару препаратлары сатып алуга китәчәк болай да кадерле акчаны янга калдырыйк дисәк, дару үләннәре җыюны һәр хуҗалыкта оештыру зарур.

## Җир турында сөйләшәбез



# 2. «Без үстерәбез, карак туена»

Шәһәрлеләр өчен бакча сезонының тәүгесе, һәм әйтергә кирәк, иң җаваплысы тәмамланды: бакчалар казылды, җиләк - җимеш агачлар эшкәртелде, яшелчә утыртылды. Кичләрен исә шәһәрлеләр, кем ничек булдыра ала шулай, бакчаларына су сибәргә, түтәлләр утарга киләләр. Һәркемнең күңелендә бер уй: уңышны күбрәк итеп җыеп алып, кышны яшелчә, җиләк - җимешкә кытлык күрмичә үткәрәсе иде. Әмма тырышлык, теләк бер нәрсә, соңгы елларда уңыш шәһәрлеләр кулына түгел, ә кеше өстеннән көн күрергә күнеккән караклар кулына керә. Узган көз бу уңайдан безнең редакциягә дә шул характердагы зар белән килүчеләр аз булмады. Район эчке эшләр бүлегеннән алынган мәгълүматлардан күренгәнчә, аларга да аерым граждannардан бакчалардан яшелчә, җиләк - җимеш урлау буенча гаризалар кергән, кайбер фактлар буенча «кайнар эздән» караклар да тотылган. Әмма бит бакча каракларыннан зыян күреп тә, бу фактны әллә ни киң таратмыйча, канлы күз яшьләре түгеп кенә калучылар да күпме әле. Җәеңне шул түтәлләргә өмет баглап, шунда казынып үткәргәч, еламаслык та түгел шул. Әле ярый өлешеңә «тәртипле» караклар туры килеп, кишерең белән кыярыңны гына тәяп китсәләр: соңгы вакытта участоклардагы дача өйләрен, андагы әйберләрне ватып - җимерү очраклары да ешайды бит. Әнә, РПУның «Дубрава» бакчачылык ширкәтендә өйләр, вагончыклар йозаксыз тора хәзер. Гаҗәпләнер урын юк: керергә теләгән кеше әллә нинди йозакны да, тәрәзәне дә вата ул.

Түбән Норлат авылы тирәсендә дача участоклары булган кешеләр дә авыл угрыларыннан зур зыян күрәләр. Киекле юлы өстендәге, чистарту корылмалары тирәсендәге бакчалар участоклары хуҗалары гөнаһны исә нигездә Норлат «бомж»ларына, эшсезләр, сәрхүшләргә сылтыйлар.

Урынлы сорау туа: бакчаларны алардан кем сакларга тиеш соң?

- Без ширкәтләргә милиция хезмәткәрләрен махсус беркетә алмыйбыз,- диде безнең соравыбызга район эчке эшләр бүлеге начальнигы урынбасары В.Л.Гаврилов. - Республиканың бары тик эре шәһәрләрендә генә шәһәр яны зонасы бакчачылык ширкәтләрен саклау буенча милициядә шуның өчен махсус хезмәт структуралары бар.

- Димәк, халык милиция ярдәменә өмет итә алмый?

.- Ала. Без җәен - көзен ширкәтләргә махсус рейдлар үткәрәбез. Халыкка да үтенечебез бар: урлау фактларының һәрберсе турында милициягә мөрәҗәгать итегез. Шулай итмәсәгез, угрылар җәза алмыйча «котырына» гына барачаклар. Без, үз чиратыбызда, гаризаларның берсен дә игътибардан читтә калдырмаячакбыз.

Аңлашылганча, милициягә ышанып була. Әмма бу әле милиция көн саен безнең бөтен бакчаларыбызны да саклап бетерә ала дигән сүз түгел. Димәк, ширкәтләр яннан ярдәм көтеп ятмыйча үзләре дә саклану чараларын күрергә тиешләрдер, мөгаен. Ә ничек итеп? Бусы инде алар мәнфәгатендә. Сүз бит ширкәт җирләре турында бара. Ширкәтнеке булгач, үстерелгән уңышны да коллектив белән, бергә сакларга кирәктер, безнеңчә.

**Р.ГИНЯЕВА.**

«Заветы Ильича» хуҗалыгында Иван Геннадьевич хезмәте әһәмиятле урынны тота: ул - аппаратчы - көйләүче. Техниканың төзеклеге аның күңел биреп эшләвенә дә бәйләнгән. Шул хезмәтендә 5 еллап эшләп ул үзен чын оста итеп таныта алды. Урып - җыю чорында ул аның белән генә чикләнми, «Полесье»га утырып кырларны да иңли.



**Рәсемдә: «Заветы Ильича» КХАсы аппаратчы - көйләүче остасы Иван Макаров.**

# МӘЧЕТ МАНАРАЛЫ БУЛДЫ

22 нче май көнне Салдакай авылында шатлыклы вакыйга булды: янып киткән мәчетебез урынына яңа мәчет төзеп манарасын торгыздык. Авыл халкы өчен күптән көтелгән бу олы, дулкынландыргыч көнгә районыбыз хакимиятеннән вәкилләр килгән иде. Алар безнең шатлыгыбызны уртаклашып, котлау - тәбрикләүләрен җиткерделәр.

Без, авыл картлары да мәчет төзү, манара торгызу кебек изге эштә көчләрен кызганмыйча ярдәм күрсәтүчеләргә ходай тәгаләнең рәхмәтен җиткерәбез. Манараны торгызуда эретеп ябыштыручылар Сәгыйт Йосыпов, Марат Хуҗаханов, балта осталары эшләрен Камил Усманов, Тәлгать Йосыпов, Кәкре Атау мәхәлләсеннән Касыйм абый Зәйнетдинов, Норлаттан килгән кранчы Вәлиулла Нәфыйговның булышлыклары зур булды.

Дөрес, әлегә мәчетебез ачылырга әзер түгел: эчтә штукатур - буяу, йөзләү, идәннәр, ишекләр кую эшләре тора. Һәм боларны гамәлгә ашыру өчен аз акча кирәкми. Шуңа да милләттәшләребезгә хәлләреннән килгәнчә, сәдака рәвешендә ярдәм кулы сузуларын сорап мөрәҗәгать итәбез. Тормышларыбыз авыр булса да, без, бер авыл халкы дуслык, туганлык рухында, уртак тел белән авылыбызда игелеклек үзәге булырга тиешле йорт - мәчетебезне бергәләшеп төзеп бетерә алсак олы куаныч булыр иде.

**ГАЯЗ НУРЕТДИНОВ.**
**Салдакай авылы.**

## *Илдә ниләр бар?*



## Газ «сикерә»

15 майдан табигый газ бәясе икеләтә диярлек артты. Үзәктән җылытулы, кайнар сулы һәм газ плитәле заманча фатир хуҗалары газ өчен ай саен кеше башыннан 1000әр сум түгел, 1700әр сум түләргә тиеш хәзер. Пар белән җылытыла торган, газ плитәле һәм колонкалы йортларда - җан башына 2000 - 3400 сум. Газ плитәсе булган, әмма кайнар су килми торган йортларда һәр кешедән айга 2800әр сум түләтелә. Үз йорты белән яшәүчеләргә газ белән җылытыла торган 1 кв.метр мәйдан өчен элекке 340 сум урынына 840 сум түлисе. Исәпләгеч җайланмасы булган хуҗалар 1 куб. метр табигый газга 110 сумнан түли.

## Сәламәтлегегез хакына


Җәмәгать туклануы хезмәтен камилләштерү һәм ризыкның сыйфатын күтәрү максатында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты ул тармакта сертификатлаштыру системасы булдыру турында карар кабул итте.

Мәҗбүри сертификатлаштыру хезмәтен гамәлгә ашыру Кулланучылар хокукын яклау дәүләт комитетына (үзәк орган), Санитария - эпидемиология күзәтчелеге дәүләт комитетына, Министрлар Кабинеты каршындагы җәмәгать туклануы идарәсенә, Татарстан Кулланучылар берлегенә йөкләнде. Сынау - лаборатория үзәкләре эшен Санэпидемиология күзәтчелеге дәүләт комитетының Казан, Чаллы, Түбән Кама, Әлмәт, Зәй, Зеленодол, Чистай оешмалары башкарырга тиеш.

## *Сөйләшү темасы - экология*

# БЕЗ ЯШИСЕ ҖИР БИТ БУ

***1993 елның августында Министрлар Кабинеты карары буенча республикада экология фонды барлыкка килде. 1994 елның февралендә ул Норлатта да ачыла. Аның максаты нидән гыйбарәт, фонд тарафыннан нинди эшләр башкарылган? Безнең корреспондентыбыз ТР экологик фондының Октябрь районы буенча өлкән белгече Сания Минтаһировна ӘҺМӘДИЕВА белән шул хакта әңгәмә корды.***



- ТР экологик фонды хуҗалык исәбендәге оешма. Табигатьтән файдалануның түләүле принцибын максатчан экологик проектлар һәм программаларны финанслау, дәүләт предприятиеләренә һәм оешмаларга табигатьне саклау буенча эшчәнлегендә практик ярдәм күрсәтү фондның хөкүмәт тарафыннан йөкләтелгән төп бурычлары булып санала. Экология фондының акча средстволары ТР территориясендә нинди ведомство карамагында булуларына карамастан, юридик һәм физик затлардан әйләнә - тирә мохитне пычрату өчен түләү рәвешендә алына. Стационар һәм хәрәкәттәге чыганаклардан атмосферага пычратучы матдәләр ташлануы: калдыкларны түгү; автотранспорт һәм предприятие объектларын юу вакытында суларга яки җиргә пычрак сулар агызу - болар һәммәсе дә әйләнә - тирә мохитне пычратуга керә.

**- Табигатьтән файдаланган өчен алына торган салым тиешенчә, ягъни файдага кулланыламы соң? Бу салым түләүчеләрне бик кызыксындыра торган сораудыр, мөгаен.**

- Октябрь районы фонд буенча көньяк - көнчыгыш бүлекчәгә керә һәм, кызганычка каршы, Татарстанның иң пычрак регионнарыннан берсе булып санала. Җирле бүлекчәдә җыелган акчаларның бүленешенә килгәндә, ул бик төгәл: 20 проценты ТР экофонды исәбенә табигатьне саклау буенча республика күләмендә үткәрелә торган чараларга күчерелә, тагын 20се әйләнә - тирә мохитне саклау Министрлыгы региональ инспекциясенең (бу экофонд түгел) матди - техник базасын ныгытуга тотыла, 3 проценты гадәттән тыш экологик чаралар һәм гамәлләр үткәрү өчен резерв фондны тәшкил итсә, барлыгы 57 проценты районда табигатьне саклау чараларын финанслауга китә.

**- Сезнең өч елдан артып киткән эш дәверегездә районда экофонд тарафыннан нинди чаралар финансланды?**

- 1994 - 96 елларда районда табигатьне саклау өлкәсендә үткәрелгән төрле чараларга 536,4 млн. сум акча бүленде. Аерым алганда, канализация чистарту корылмалары өлешчә реконструкцияләнде, Төрнәс авылын әйләнеп уза торган каналда тирәнәйтү эшләре алып барылды, су чистарту корылмалары киңәйтелде, чишмәләр чистартылды һәм төзекләндерелде. Каты көнкүреш калдыклары полигоны проекты ясауда, Зур Чирмешән елгасында су күтәрткеч плотинаны төзүгә дә безнең фондтан акча бүленде.

1997 нче елда районга 2.85 млрд.сумлык акча бүленү каралган. Бу сумманы су чистарту корылмаларын киңәйтүдә (500 млн. сум), Зур Чирмешән елгасында Шандор плотинасы төзелешендә (1400 млн.), Дала Мамыгыннан Норлатка кадәр суүткәргеч төзүдә (450 млн.), каты көнкүреш калдыклары полигоны төзелешендә (500 млн.) кулланырга ниятлибез.

**- Предприятиеләрнең экофондка бурычлары зурмы, әллә үзвакытында түләп баралармы?**

- Предприятиеләрнең финанс хәле чиктән тыш авыр булуга карамастан, экофондка акча күчерүне кичектермичә гамәлгә ашыручылар да бар. Мәсәлән, «Татнефтепродукт» АҖ, элеватор, икмәк заводы, «Сөт - май комбинаты» АҖ, НУГР, райпо, РСУ, ОРП шундыйлардан. Кызганычка каршы, бурычлары шактый җыелган предприятиеләр дә аз түгел. «Машина төзү заводы», «53 нче СМУ» ОООсы, «Шикәр заводы», МСО, «Сельхозтехника» АҖ, АТП, «Агрохимсервис» АООТы, сәүдә базасы, ДРСУ, «Төрнәс» спирт заводы ДУПы һәм башкалардан 100 млн. лап акча аласыбыз бар. Бу күренеш исә алда санап кителгән табигатьне саклау чараларына акча күчерү чыганагын киметәчәк дигән сүз. Ә без әле әйләнә - тирә мохитнең чисталыгы белән мактана алмыйбыз, шуңа да районыбыздагы экологик хәлне яхшырту бәрабәренә халык сәламәтлеген ныгыту, генофондны саклау безнең фондның төп юнәлеше булып тора.

**- Фонд тагын башка төрле чараларда катнашмыймы?**

- ТР экофонды бу хакта кайгыртып, балаларга экология дәреслекләрен өлешчә бушлай таратты. «Экология» кебек фән әлегә яңа булып кала, шуңа күрә югары белгечле укытучылар да җитешми. Фонд бу мәсьәләне дә игътибардан читтә калдырмады: Татарстанның көньяк - көнчыгыш районнарында, шул исәптән Норлатның 3 нче мәктәбе базасында да экология фәнен алып баручы укытучылар белән семинар үткәрелде. Анда ТР экофонды, югары белем учреждениеләре белгечләре чыгыш ясады. Алар укытучыларны кызыксындырган байтак кына сорауларга җаваплар бирделәр.

**- Сания Минтаһировна, безнең газета укучыларыбызга бу җәһәттән ни әйтер идегез?**

- Экологик хәл безнең һәммәбез өчен дә зур бәла һәм аңа бәйле мәсьәләләрне хәл итү һәркайсыбызның проблемасы булырга тиеш. Без сулыйсы һава, без яшисе җир бит бу. Менә шул хакта аңласыннар иде.

**Әңгәмәдәш - Ф.ЗЫЯТДИНОВА.**



# Безгә театр килә...

***6 - 14 июньдә Кәрим Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театры безне үзенең ел репертуарына кергән «Гайфи бабай, өйлән давай!..» исемле музыкаль комедиясе белән таныштырачак.***



Татар театрының туксан еллык тарихында Кәрим Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театры буларак танылган коллектив үзенчәлекле урын биләп тора. 1993 елда аның оешуына 60 ел тулды. Авыл тормышын аякка бастыру, колхозчыларны мәдәниятле итү максаты белән оештырылган театр бу изге бурычын намус белән башкара. Аның ярты гасырдан артык гомере тәгәрмәчләр өстендә үтә, шуңа да аны якын итеп «авыл театры» дип тә йөртәләр.

Театрның иҗат юлы бай һәм катлаулы. Бу аның соңгы еллардагы репертуарына гына карагач та ачык күренә: «Хаҗи әфәнде өйләнә» (Ш.Камал), «Без бит авыл малае» (Т.Миңнуллин), «Кара йөзләр» (М.Гафури), «Хикмәтле доклад» (К.Тинчурин), «Мәкәрҗәгә барган идек» (И.Юзеев), «И,машина, машина, җитте минем башыма» (Р.Вәлиев), «Урланган мәхәббәт (Н.Хикмәт), «Баҗа мал түгел, кәҗә туган түгел» (Т.Миңнуллин), «Сихерче» (Н.Гыйматдинова) һәм башка сәхнә әсәрләре тамашачыга аеруча таныш. Берничә ел элек коллектив безнең районда Р.Ханнановның «Имансызлар» пьесасы белән булып китә. Ә хәзер Гөлшат Зәйнәшева әсәре - пьесасы буенча режиссер Рәшит Заһидуллин куйган «Гайфи бабай, өйлән давай!..» спектаклендә театрның күренекле, талантлы артистлары катнаша. Төп рольдә Татарстанның халык артисты Наил Шәйхетдинов (ул күрше Чирмешән районыннан), Татарстанның атказанган артисткалары Зөләйха Хәкимҗанова, Ләлә Миңнуллина, Роза Хәбибрахманова, артистлар Харис Төхфәтуллов, Нурия Вәлиева, Ринат Шәмсетдинов, Миләүшә Нәҗмиева уйныйлар. Спектакльнең музыкаль өлешен ТРның атказанган сәнгать эшлеклесе Мәсгүт Имашев эшләгән. Калганын тамашачы үзе килгәч күрер...

***Театрның маршруты түбәндәгечә:***
***6 май - Киекле***
***7 май - Югары Норлат***
***8 май - Яңа Иглай***
***9 май - район мәдәният йорты***
***10 май - Бикүле***
***11 май - Иске Әмзә***
***12 май - Кычытканлы***
***13 май - Әлмәт***
***14 май - Колбай Мораса.***
***Билет бәясе 10 мең сум.***

**Рәсемдә: спектакльдән күренеш.**



# Зур тормышка әзерли

Чулпан урта мәктәбе коллективының үзеген тәҗрибәле, эзләнеп эшләүче педагоглар тәшкил итә. Лидия Ивановна Егорова - шуларның берсе. Ул менә инде 34 ел бертөзлексез биредә балаларга рус теле һәм әдәбияты укыта. Дәресләрен оста оештыра ул, алар бер - берсен кабатламый. Лидия Ивановна хезмәттәшләре белән һәрчак яхшы мөгамәләдә, балалар белән дә уртак тел таба. Хәзер ул балалардан имтиханнар кабул итә.

**Рәсемдә: Л.Егорова.**
**Н.АЗИЗОВ фотосы.**

## Очрашуга чакырабыз



***1997 елның 7 июнендә иртәнге сәгать 9да Киекле мәктәбен 1982 елда «В» классында тәмамлаучыларның очрашуы була.***



***3 нче мәктәпне 1977 нче елда тәмамлаучылар очрашуы 1997 елның 5 июлендә була.***


## Акционерлар игътибарына!

**«Норлат - Октябрь сөт - май комбинаты» АҖсе акционерларының гомуми җыелышы 1997 елның 27 июнендә комбинатның кызыл почмагында 13 сәгатьтә үтәчәк. Адрес: Норлат шәһәре, Гыйматдинов ур., 142а. Акционерларны теркәү 12 сәг.тә башлана.**

**Җыелышның көн тәртибе:**

**1. Санау комиссиясен сайлау.**
**2. 1996 ел өчен еллык отчетны, бухгалтерлык балансын, табыш һәм зыян счетларын раслау.**
**3. Ревкомиссия отчеты.**
**4. Директорлар Советын сайлау.**
**5. Ревизия комиссиясен сайлау.**
**6. Аудитор турында мәсьәлә.**

**Теркәү вакытында паспорт булу шарт. Башка акционерларга ышаныч кәгазе биреп, үз урыныгызга вәкаләтле кешеләр юллый аласыз.**

«Норлат - Октябрь сөт - май комбинаты» директорлар Советы.

## Предприятиеләр, оешмалар баш бухгалтерлары, җитәкчеләре игътибарына!

Агымдагы инвентаризациягә бина корылмаларын бәяләргә, кабат бәяләргә заявкалар кабул итәбез.

Хосусыйлаштырылган фатир ияләреннән техник паспортларын килеп алуларын сорыйбыз.

**Техник инвентарьлаштыру бюросы.**

## Төрлесеннән

**Россия Саклык банкының гадәти һәм өстенлекле акцияләрен сатып алам**. Тел.: 5 - 29 - 95.

***

**Кошкида авариягә эләккән транспортны бәяләүче автоэксперт эшли**. Тел.: 2 - 28 - 28.

***

**«Норлат - Октябрь» сөт - май комбинатына даими эшкә сыек һәм газ ягулыгында эшләүче котельняларга операторлар кирәк**. Адрес: Норлат шәһәре, Гыйматдинов ур., 142.

## Белдерүләр

## Сатабыз

**Ашыгыч төстә Югары Норлатта йорт яны корылмалары белән яңа йорт, газ белән җылытыла.** Адрес: К.Маркс ур., 27 - 2, тел.: 2 - 25 - 47.

***

**Мунча өчен 3 х 5 метрлы бура.** Адрес: Синдряков ур., 25 - 25 яки Салдакайда Азяковларга мөрәҗәгать итәргә.

***

**Җылыту торбалары**. Маслозаводская ур., 3.

***

**«Москвич - 2140», 35 мең км. юл үткән, ремонт таләп итми.**

**Шәхси йорт 1 яки 2 бүлмәле фатирга алыштырыла.** Тел.: 2 - 14 - 85.

***

**5,5 х 11 метрлы яңа йорт бурасы, барлык пычкы материаллары белән.** Адрес: Завод ур., 2 - 16, 18 сәг.тән соң.

***

**Хосусыйлаштырылган фатир**. Тел.: шикәр заводы коммутаторы аша 4 - 69, 5 - 13 - 21 (арадашчы).

***

**1980 елгы «Москвич - 412» машинасы, кыйммәт түгел.** Карл Маркс проспекты, 6 - 7.

***

**«Нива» автомашинасы**. Красноармейская ур., 61а - 13, тел.: 2 - 14 - 05.

***

**Яхшы хәлдәге ВАЗ - 21013 автомашинасы**. Космонавтлар ур., 35 - 1а (16 сәг.тән соң).

***

**«Орион» телевизоры**. Бәясе 1,5 млн. сум. Тел.: 5 - 28 - 15.

***

**1994 елның сентябрендә чыккан «Нива» ВАЗ - 21213.** Тел.: 2 - 28 - 28 (эш), 2 - 24 - 03 (өй).

***

**1985 елгы ВАЗ - 2121**. Тел.: 4 - 02 - 54.

***

**72500 км. юл үткән ВАЗ - 2101**. Тел.: 2 - 12 - 71.

***

**Советская ур., 57 - 36 адресында 2 бүлмәле фатир. 18 сәг.тән соң мөрәҗәгать итәргә.**

***

**Хуҗалык исәпле җәмәгать туклануы предприятиеләре универмагның бер бүлегендә «Горка - 2» стенкасы (2.850.000 сум), кадак, гардин полотносы сата.**

***Самара өлкәсенең Кошки авылында, Новая ур., 4 йортта «Промтоварлар» кибете ачылды. Сатуда видео - аудио - көнкүреш техникасы, телефоннар, төзелеш материаллары: шифер, цемент, электродлар, краска, кадак, олифа, махсус киемнәр, эш кораллары; «Стинол» суыткычы, мотоблоклар, мини - ашлык ярдыру җайланмалары бар, күп товарларны җитештерүче заводлардан алганлыктан, бәяләр базар бәясеннән арзан. Без гарантияле һәм гарантиядән соң хезмәт күрсәтү алып барабыз. Түләү тәртибе - теләсә нинди. Оешмалардан һәм шәхси затлардан өйгә китереп бирү шарты белән заявкалар кабул итәбез.***

Тел.: (650) - 2 - 18 - 65.


## Документлар югалды

**1992 елның 30 июнендә Октябрь район мәгариф бүлеге тарафыннан Власова Лиля Владимировна исеменә бирелгән 013456 номерлы таныклык югалу сәбәпле гамәлдән чыккан дип исәпләргә.**

***

**1986 елда Норлат кичке мәктәбе тарафыннан Мусина Заһирә Харисовна исеменә бирелгән АВ 022185 номерлы урта белем турында таныклыкны югалу сәбәпле гамәлдән чыккан дип санарга.**

***

**Исхаков Фаил Вәлиярович исеменә машина йөртү таныклыгы, машина йөртүгә ышаныч кәгазе, Салахов Рөстәм Минсәлимович исеменә техпаспортны югалу сәбәпле гамәлдән чыккан дип исәпләргә.**


## Идел Буе региональ наркология үзәге

*Алкогольгә бәйлелектән һәм тәмәке тартудан бер сеанста кодлаштыру.*

***Табиб М.Б.Багрянцев.***

**Бездә генә!**

**Тулы анонимлык. Индивидуаль якын килү. Дәвалау барышында пациентның туганнарына да катнашырга рөхсәт ителә. Белешмә бирелә. Консультация, әңгәмә, кодлаштырудан соң күзәтү һәм ярдәм - бушлай!**

**Язылу һәм әңгәмә дәвалау көнне пәнҗешәмбе көндезге 5, 20 июньдә сәгать 2дә район мәдәният йорты бинасында уздырыла.**

РФ Сәламәтлек саклау министрлыгыннан 1995 елның 16 гыйнварында бирелгән № 00164 - 30 лицензия.



БАШ МӨХӘРРИР **Р.Ф.ҖАМАЛИЕВ.**

МӨХӘРРИР **С.Н.ХӘЙРУЛЛИНА**

Учредительләр: Октябрь район хакимияте һәм редакциянең хезмәт коллективы.

"Дуслык" район газетасы атнаның чәршәмбе, җомга, шимбә көннәрендә чыга, рус һәм чуваш телләренә тәрҗемә ителә.

Безнең адрес: 423000, Татарстан Республикасы, Норлат шәһәре, Карл Маркс урамы,19.

Телефоннар: баш мөхәррир - 2-12-14, 2-22-81, мөхәррир һәм авыл хуҗалыгы бүлеге - 2-22-51, Советлар һәм җәмәгать оешмалары тормышы, чуваш теленә тәрҗемә буенча мөхәррир - 2-10-44, җаваплы сәркәтип - 2-18-67, рус теленә тәрҗемә буенча мөхәррир - 2-14-16, бухгалтерия,реклама бүлеге, фотокорреспондент - 2-15-63.

*Газета Татарстан Республикасының мәгълүмат һәм матбугат Министрлыгында 34 нче номерлы таныклык белән теркәлде.*

Ульяновск өлкәсе матбугат һәм мәгълүмат идарәсенең Димитровград типографиясе. Офсет ысулы белән басылды. Күләме - 1 басма табак. Тираж 2089 данә. Заказ N 7204